**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ОЛЫ АЧАСЫР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

30 нчы декабрь 2015 ел №35

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 нче июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы нигезендә 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Җирле референдум турында» 2004 елның 23 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 10 статьясы, «Олы Ачасыр авыл җирлеге Башкарма комитетының 2015 елның 28 декабрендәге 24 номерлы «Җирле референдум үткәрүне оештыру турында»гы карары, Олы Ачасыр авыл җирлеге Советының 2015 елның 28 декабрендәге «Җирле референдумны үткәрү инициативасы турында»гы 34 номерлы карары нигезендә Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге Советы Советы **карар итте:**

1. 2016 елның 6 мартына Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2016 елда Олы Ачасыр авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешедән 100 сум күләмендә үзара салым акчасын кертүгә һәм алган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме?:

| № | Гражданнарның үзара салым акчаларын тоту юнәлеше | Гражданнарның үзара салым акчаларын тоту күләме (сум) |
|---|---|---|
| 1. | Янгын гидрантлары урнаштыру | 22000 |
| 2. | Ирекле янгын сүндерү машинасын тоту | 8000 |

| | | |
|---|---|---|
| | (электр энергиясенә түләү) | |
| 3. | Ирекле янгын сүндерү машинасын тоту (запас частьләр сатып алу, ягулык-майлау материаллары, страховка рәсмиләштерү) | 10000 |
| 4. | Чишмәләрне агымдагы һәм капиталь ремонтлау | 21100 |

«ӘЙЕ» «ЮК» .

3. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук мәгълүмат стендларында: Олы Ачасыр авылы, Үзәк урамы, 46 йорт (җирлек хакимияте бинасы), Олы Ачасыр авылы, Кооператив урамы, 26 йорт (авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

**Олы Ачасыр авыл жирлеге**
**башлыгы урынбасары, Совет рәисе Р.С. Кадиров**